ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитеты**
Кама Тамагы районы,
Тәмте авылы
тел. 8-(277)- 31-1-76

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Теньковского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Теньки
тел. 8-(277)- 31-1-76

# КАРАР

**№ 11** **09.04.2019**

2018 елның 18 декабрендәге “Документлар күчермәсенең дөреслеге һәм алардан өземтә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитетының 16 номерлы Карары белән расланган документлар күчермәләренең дөреслеге һәм алардан өземтәләр турындагы муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон, 2010 елның 27июлендәге 210-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль закон, 2017 елның 6 июнендәге “Җирлекләрнең җирле администрацияләре башлыклары һәм җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турындагы инструкцияне раслау турында”гы Россия Федерациясе юстиция Министрлыгының 97 Боерыгы нигезендә, муниципаль районнарның җирле администрацияләре башлыклары һәм муниципаль районнарның җирле үзидарә органнарының махсус вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КЫЛА**:

1. 2018 елның 18 декабрендәге “Документлар күчермәсенең дөреслеге һәм алардан өземтә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитетының 16

номерлы Карары белән расланган документлар күчермәләре һәм алардан өземтә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

регламентның 2.5 бүлегендәге 2 пунктының 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Аларның күләме бер биттән артып киткән күчермә яки өземтәләрнең дөреслеген таныклау өчен тәкъдим ителгән документлар аларны беркетү юлы белән яки аларның бөтенлегенә шик тудырмый торган башка ысул белән тәэмин ителергә тиеш.”;

регламентның 2 бүлегенең 2.9 пунктының икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигез каралмаган.

Баш тарту өчен нигез:

1) мондый гамәлләр башкару Россия Федерациясе законнарына каршы килә;

2) гамәл башка җирлек яки муниципаль районның җирле үзидарә органының вазыйфаи заты тарафыннан (мирас мөлкәтен саклауга карата чаралар кабул итүгә карата һәм кирәк булган очракта аларга идарә итү буенча чаралар күрүгә карата кулланылучы) яисә нотариус тарафыннан башкарылырга тиеш;

3) нотариаль гамәлләр башкару турында үтенеч белән эшкә яраксыз граждан яисә кирәкле вәкаләтләренә ия булмаган вәкил, яшәү урыны буенча теркәлмәгән яисә җирлектә тору урыны буенча теркәлмәгән граждан мөрәҗәгать иткән;

4) мөрәҗәгать итүче тарафыннан документлар тулы күләмдә тапшырылмаган, яисә тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат бар.”;

регламентның 2 бүлегендәге 2.10 пунктының икенче абзацында җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Физик һәм юридик затлар өчен дәүләт пошлинасын түләү буенча ташламалар Россия Федерациясе Салым кодексының 333.35 маддәсенең 1 пунктының 11, 12 пунктчалары, 333.38 маддәсе белән билгеләнгән.”.

2. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы Тәмте авылы, 2 нче Октябрь урамы, 50 нче йорт ( мәдәният йорты бинасы)

- ТР, Кама Тамагы районы Тәмте авылы, Октябрь урамы, 65 йорт ( АҖ администрациясе бинасы),

шулай ук Хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Җитәкче** **И. А. Зиновьев**